Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Федотовка авыл җирлеге
Кузьминовка авылында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2021 елның 20 ноябре №1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлегенең Кузьминовка авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 20 ноябрендә 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлеге Кузьминовка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, беренче төркем инвалидлар, сугыш ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлар, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, 600 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

- Федотовка авыл җирлеге Кузьминовка авылы торак пункты чикләрендә юлларны карап тоту;

- МТЗ-82.1 тракторын тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча түләү)

«ӘЙЕ» «ЮК».

соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Халык җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 76 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 39 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучылар бертавыштан «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирделәр.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлегенең Кузьминовка авылында гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлеге составына керүче Кузьминовка авылында гражданнар җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Федотовкаавыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр

балигъ булган яшәүчедән, беренче төркем инвалидлар, сугыш ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлар, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш 600 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

- Федотовка авыл җирлеге Кузьминовка авылы торак пункты чикләрендә юлларны карап тоту;

- МТЗ-82.1 тракторын тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча түләү)

карарын кабул ителгән, дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Федотовка авылы, Совет урамы, 6 (җирле үзидарә бинасы), Совет урамы, 8 (авыл мәдәният йорты), Кузьминовка авылы, Кооператив урамы, 10 йорт (авыл клубы) адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Федотовка авыл җирлеге башлыгы В.И.Павлова